| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 27.03.2019 ел | 104 |

Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2014 елның 20 июнендә кабул ителгән 98нче номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүчеләрнең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хәлләре яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны исәпкә кертү тәртибе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2нче һәм 28нче статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 октябрендә кабул ителгән 387-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы шәһәр Советының 2014 елның 20 июнендә кабул ителгән 98нче номерлы «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүчеләрнең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи хәлләре яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алулары турында хәбәр итү, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, аны сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаны исәпкә кертү тәртибе турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“муниципаль вазыйфа биләүче зат – депутат, җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлана торган вазыйфаи заты, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенең даими нигездә эшләүче һәм юридик зат булган, хәлиткеч тавыш хокуклы әгъзасы»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе — Р.Х. Гатиятуллин